# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге составына керүче Гришкино торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 13 «19» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегенең Гришкино торак пунктында 2023 елның «19» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Гришкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләреннән кала, 2024 елда 700 (Җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Кызыл Байрак урамындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю);
-урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, алмаштыру;
-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 107 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 56 кеше, 52,5% тәшкил итә:
Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 56 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ»позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегенең Гришкино торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныргa.

2. Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегенең Гришкино торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Гришкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләреннән кала, 2024 елда 700 (Җиде йөз) сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Кызыл Байрак урамындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю);

-урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, алмаштыру;

-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

3. Әлеге карарны Көек-Ерыкса авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Ф.Р.Шәйхетдинов